ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

08.05.2020 ел Баулы шәһәре №100

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының 2009 елның
7 ноябрендәге «2020 елга Баулы
муниципаль районының мәктәпкәчә
белем бирү программаларын тормышка
ашыручы мәгариф оешмалары
эшчәнлеген финанслау нормативларын
раслау турында»гы 311 номерлы
карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр
кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында»гы 2009 елның 2 июлендәге 546 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 7 ноябрендәге «2020 елга Баулы муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында»гы 311 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1нче пунктка:

4нче абзацта «күчеш чорына күләмгә» сүзләреннән соң «составында абонент түләве» сүзләрен өстәргә;

5нче абзацта:

- «күчеш чорына күләмгә» сүзләреннән соң «составында абонент түләве» сүзләрен өстәргә;

- «0,87» санын «0,85»гә алмаштырырга;

- «0,89» санын «0,865»гә алмаштырырга;

- 3нче кушымта исемендә «күчеш чорына күләмгә» сүзләреннән соң «составында абонент түләве» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров